РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

28 май, 2026 ел Кукмара ш. № 47

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 90 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Кукмара районы прокурорының 2026 елның 29 мартындагы 02-08-01 номерлы протестын карап, Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 90 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәгә (2021 елның 17 декабрендәге 96 номерлы, 2023 елның 27 апрелендәге 196 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 224 номерлы, 2024 елның 29 мартындагы 241 номерлы, 2024 елның 27 декабрендәге 285 номерлы, 2025 елның 11 апрелендәге 301 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.7. пунктын өстәргә:

«1.7. Профилактик визит үткәрү турында, кисәтү игълан итү турында, контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тота торган контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү турында карарлар, дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) махсус режимы кысаларында контроль (күзәтчелек) чарасы (шул исәптән уздыру мөмкинлеге булмау турындагы актлар), профилактик чара, контроль (күзәтчелек) гамәл актлары, ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында кисәтүләр контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрына алар турында белешмәләр кертү һәм аларга имза салу юлы белән рәсмиләштерелә. Күрсәтелгән карарларны, актларны һәм күрсәтмәләрне рәсмиләштерү өчен, документны аерым төзү таләп ителми.»;

1.2. 2.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Контроль объекты, белешмәләрне контроль төрләренең Бердәм реестрына керткәннән соң, хәвеф-хәтәр категорияләренең берсенә кертелгән дип санала.»;

1.3. 2.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеген раслау турындагы норматив хокукый актта контроль объектлары параметрларының конкрет кыйммәтләре йә аларны исәпләү һәм (яисә) хәвеф-хәтәр индикаторларын куллану тәртибе булырга мөмкин.»;

1.4. 3.3.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Контрольдә тотылучы зат кисәтүне алган көннән алып ун эш көне эчендә Контроль органына кисәтүгә карата, шул исәптән Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы аша, каршылык белдерергә хокуклы.»;

1.5. 3.4.1 пунктында «вәкилләренең» сүзләреннән соң, «шул исәптән Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы аша җибәрелгән» сүзләрен өстәргә;

1.6. 3.4.2 пунктының 1) пунктчасында «видео-конференц-элемтә,» сүзеннән соң «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдалану,» сүзләрен өстәргә.»;

1.7. 3.5.4. пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Контрольдә тотылучы затка мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында, башланырга егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә хәбәр ителә.»;

1.8. 4.5.1. пунктына түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Документлар контрольдә тотылучы затлар тарафыннан Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы һәм «Инспектор» мобиль кушымтасы ярдәмендә тапшырылырга мөмкин.»;

1.9. 4.5.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.4. Әгәр контроль (күзәтчелек) органы карамагында булган белешмәләр һәм документлар җитәрлек булмаса, документлар буенча тикшерү барышында түбәндәге контроль (күзәтчелек) гамәлләр башкарылырга мөмкин:»;

1.10. 4.6.6. пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Күчмә тикшерүләрне уздыру срокларына һәм күчмә тикшерүләр уздыру барышында кече эшкуарлык субъектлары белән үзара хезмәттәшлек итү срокларына карата таләпләрнең гамәлдә булуы кече оешмалар өчен «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 1.1 өлешенең 2 пункты белән билгеләнгән чик күрсәткечтән алдагы календарь ел өчен хезмәткәрләрнең уртача исемлектәге саны артмый торган социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга, ә микропредприятиеләргә күчмә тикшерүләр уздыру өлешендә – микропредприятиеләр өчен әлеге пункт белән билгеләнгән чик күрсәткечтән алдагы календарь ел өчен хезмәткәрләрнең уртача исемлектәге саны артмый торган социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга кагыла.»;

1.11 4.9.2 пунктының икенче абзацында «карау гамәлгә ашырылырга» сүзләреннән соң «шул исәптән пилотсыз аппаратлар (системалар) кулланып» сүзләрен өстәргә.»;

1.12. 4.2.3. пунктына түбәндәге эчтәлекле 3 нче абзацны өстәргә:

«Әлеге Федераль законның 1 өлешендәге 3, 4 һәм 6 пунктларында, 57 статьясындагы 3 өлешендә, 60 статьясындагы 2 өлешенең 3 пунктында каралган контроль (күзәтчелек) чаралар йомгаклары буенча кабул ителгән карарның үтәлешен әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән контроль (күзәтчелек) чаралар уздыру юлы белән бәяләүне үткәрү прокуратура органнары белән килештерүне таләп итми.»;

1.13. 5.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Контроль орган карарына, вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган вакыт эчендә бирелергә мөмкин.

Контроль органы күрсәтмәсенә шикаять 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган вакыт эчендә бирелергә мөмкин.

Шикаять бирү вакыты җитди сәбәпләр аркасында узып киткән очракта, шикаять бирүче затның үтенече буенча бу срок вәкаләтле орган тарафыннан кире кайтарылырга мөмкин.

Шикаять биргән кеше, шикаять буенча карар кабул ителгәнче, аны кире ала ала. Шул ук вакытта шикаятьне шул ук нигезләр буенча кабат җибәрү рөхсәт ителми.

Шикаятьтә Контроль органның шикаять ителә торган карарын үтәүне туктату турында үтенеч булырга мөмкин.»;

1.14. 5.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Шикаятьне карарга вәкаләтле орган 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган вакытта әлеге Федераль законның 40 статьясындагы 10 өлешендә каралган карарларның берсен кабул итә.

Шикаять белдерелә торган карарның үтәлешен туктатып тору турындагы үтенечнамә буенча карар турындагы мәгълүмат шикаять биргән затка 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган вакыт эчендә җибәрелә.»;

1.15. 5.9 пунктта «шикаять алынган көннән алып биш эш көне» сүзләрен «248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган вакытта» сүзләренә алмаштырырга;

1.16. 5.11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.11. Контроль органы шикаятьне карау барышы турында мәгълүматны контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә карата судка кадәр шикаять бирүнең ярдәмче системасына тапшыруны тәэмин итә. Дәүләт серен яки закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматлар һәм документлар булган шикаятьне карау Россия Федерациясенең дәүләт сере яки закон белән саклана торган башка сер турындагы закон таләпләрен үтәп, контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә карата судка кадәр шикаять бирүнең ярдәмче системасын кулланмыйча башкарыла»;

1.17. 5.13 пунктының икенче абзацында «сорату җибәрелгән вакыттан алып биш эш көне» сүзләрен «248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган вакытта» сүзләренә алмаштырырга;

1.18. 5.15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.15. Шикаятьне карау йомгаклары буенча шикаятьне карарга вәкаләтле орган 248-ФЗ номерлы Федераль законның 43 статьясындагы 6 өлешендә каралган карарларның берсен кабул итә.»;

1.19. 5.16 пунктның беренче абзацында «ул кабул ителгән көннән бер эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев